ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«3» июнь 2021 ел №400

**Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру буенча Комиссия турында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өлкәсендәге сәясәтне камилләштерү максатыннан, "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы, "Татар телен Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак куллану турында" 2013 елның 12 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны алга таба гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында" 2008 елның 27 июнендәге 451 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру буенча комиссия төзергә һәм аның составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру комиссиясе турындагы Нигезләмәне (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р.Мөхәрәмов

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
03.06.2021 ел, № 402 карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру буенча комиссия**
**СОСТАВЫ**

Комиссия рәисе:

Мөхәрәмов Р.Р. - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;

Рәис урынбасары:

Мөхәммәтшина А.Т. - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;

Комиссии секретаре:

Бәхтиярова Г.С. -Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе баш белгече

Комиссия әгъзалары:

Галимуллин Р.Н. -Арча район Советы Аппараты җитәкчесе (килешү буенча);

Гапдерахманова Г.Ә. -Арча район Советының гомуми оештыру бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Фәйзрахманова Э.М. - Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының гомуми оештыру бүлеге башлыгы;

Сәгыйтова Л.Г. -Арча район Советының юридик мәсьәләләр бүлеге башлыгы (килешү буенча)

Мөхәмәдияров Р.Д. -Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" муниципаль учреждениесе башлыгы;

Әюпов И.И. -Арча муниципаль районы Башкарма комитетының

"Мәдәният идарәсе" муниципаль учреждениесе башлыгы;

Габделгазизов И.Н. -Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы;

Фазыйлов Р.Р. -Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы;

Фәтхуллин А.Р. - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати-коммуникацион технологияләр һәм мәгълүматны яклау секторы мөдире;

Галимуллина Г.Х. -Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы;

Насыйбуллин И.Р. -"ТАТМЕДИА" АҖ нең "Арча-информ" филиалы директоры (килешү буенча).

Хәмидуллина Р. Ш. -"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы ветераннары (пенсионерлары)" Җирле иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча);

Гарипов Ш. З. -«Казан арты» тарих-этнография музее» муниципаль бюджет учреждениесе директоры урынбасары (килешү буенча);

Мифтахова Г. Ә. -«Арчаның 4 нче башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль гомуми белем бирү бюджет учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы (килешү буенча);

Касыймов Р.Ф. -Арча муниципаль районы Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча);

Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
03.06.2021 ел, №400 карарына
2 нче кушымта

**Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру буенча комиссия турында Нигезләмә**

1. Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру комиссиясе (алга таба - Комиссия) телләрне үстерү һәм гармонияле үзара бәйләнеш, милли тел мөнәсәбәтләренең тотрыклы балансын саклап калуга юнәлдерелгән сәясәтне тормышка ашыру максатларында төзелде һәм Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы даими эшләүче орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларына, әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары:

- "Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" дәүләт программасын тормышка ашыру буенча җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар, учреждениеләр һәм уку йортларының үзара хезмәттәшлеген һәм аларның эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыру;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны үтәү буенча җирле үзидарә органнары, мәгариф һәм башка оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләрнең эшчәнлеген анализлау, үз вәкаләтләре чикләрендә тәкъдимнәр һәм карарлар кабул итү, аларның үтәлешен тикшереп тору;

- Татарстан Республикасы дәүләт телләре турында Татарстан Республикасы Законнарын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары йөкләмәләрен үтәү.

4. Комиссиянең хокуклары:

- Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны үтәү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр эшләү һәм карауга кертү;

- Комиссия эше өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан

Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук учреждениеләрдән, оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан комиссия эше өчен кирәкле мәгълүматны соратып алу;

- үз компетенциясе чикләрендә муниципаль норматив хокукый актларны үзгәртү турында тәкъдимнәр эшләү һәм җирле үзидарә органнарына кертү;

- җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының, иҗтимагый берләшмәләрнең, мәдәният һәм сәнгать оешмаларының, фәнни, белем бирү һәм башка оешмаларның, шул исәптән телләр өлкәсендә сәясәтне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлек алып баручы иҗтимагый берләшмәләрнең, мәдәният һәм сәнгать оешмаларының, фәнни оешмаларның, шул исәптән коммерциячел булмаган оешмаларның вәкилләрен үз утырышларына чакыру һәм хисапларын тыңлау;

- Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар, шул исәптән телләр өлкәсендә сәясәтне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлек алып баручы коммерциячел булмаган оешмалар, Комиссия компетенциясенә караган актуаль мәсьәләләр буенча үз вәкилләрен җибәрү;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә җәмгыять тормышының барлык өлкәләрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләренең тигез хокуклы һәм оптималь эшләвен тәэмин итүгә, аларның үзара хезмәттәшлеген һәм алга таба үсешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларның инициаторы булу.

5. Комиссиянең бурычлары:

- Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы Татарстан Республикасы Законнарын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының йөкләмәләрен билгеләнгән вакытта үтәү;

- Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә һәркем өчен мөмкин булган мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итү буенча чаралар күрү;

- гражданнар һәм оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт телләре турындагы законнары таләпләрен үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрү;

- Арча муниципаль районы территориясендә һәм аның составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә Татарстан Республикасы дәүләт телләре турында Татарстан Республикасы законнары таләпләрен үтәүнең торышы турында хәбәр итү;

6. Комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары составында төзелә, алар Комиссия эшендә җәмәгать башлангычларында катнаша. Комиссия составы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

7. Комиссия рәисе-Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе.

8. Комиссия утырышлары Татарстан Республикасы дәүләт телләре турында Татарстан Республикасы законнарын Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетында гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләр нәтиҗәләре буенча айга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә уздырыла.

9. Көн тәртибен әзерләүне һәм Комиссия утырышларын үткәрүне оештыруны, шулай ук Комиссия эшчәнлегенең агымдагы мәсьәләләрен хәл итүне комиссия рәисе урынбасары, нәтиҗәләрне исәпкә алып, Комиссия секретаре белән берлектә башкаралар.

Көн тәртибе, Комиссия утырышын үткәрү датасы һәм тәртибе Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә. Кирәк булган очракта Комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

Комиссия әгъзаларына утырышның датасы һәм вакыты турында Комиссия секретаре тарафыннан 3 көн алдан хәбәр ителә.

10. Комиссия үз эшчәнлеген аның утырышларында кабул ителә һәм Комиссия рәисе тарафыннан раслана торган эш планнары нигезендә башкара.

11. Комиссия утырышын Комиссия рәисе яисә аның кушуы буенча Комиссия рәисе урынбасары үткәрә.

12. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрендәге учреждениеләр һәм оешмалар мәнфәгатьләрен кайгыртучы Комиссия әгъзалары, Комиссия утырышында шәхсән катнашу мөмкин булмаганда, үз оешмасының башка вәкилен җибәрә.

13. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

14. Комиссия карарлары Комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Комиссия карарлары тәкъдим итү характерына ия, Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы Татарстан Республикасы законнарын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләр беркетмәләрен үтәү йөкләмәләреннән тыш.

Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы Татарстан Республикасы Законнарын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча киңәшмә беркетмәләрен үтәү Комиссия әгъзалары өчен мәҗбүри.

15. Комиссия карарларының үтәлешен Комиссия секретаре контрольдә тота.